КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 март г.Казань № 274

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 сентябрь, 717 нче, 2011 ел, 21 июнь, 497 нче, 2012 ел, 17 июль, 610 нчы, 2014 ел, 23 гыйнвар, 33 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта «һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү бүлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын төзү турында нигезләмәдә:

1 пунктта:

«а» пунктчасында «бюджет, салым һәм тариф» сүзләрен «бюджет һәм салым» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы икътисады яшәешенең сценар шартларын, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын хуплый;»;

«в» пунктчасында «күләме» сүзен «иң чик күләмнәре» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «бүлү» сүзеннән соң «иң чик күләмнәре» сүзләрен өстәргә;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;»;

түбәндәге эчтәлекле «д$^1$» пунктчасын өстәргә:

«д$^1$) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп характеристикаларын фаразлауны хуплый;»;

«е» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

беренче абзацта «эшкәртүне» сүзен «төзүне» сүзенә алмаштырырга, «төзүдә катнаша» сүзләрен «эшкәртүдә катнаша» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында татар текстында «сәясәте» сүзенә кадәр «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «а$^1$» пунктча өстәргә:

«а$^1$) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп характеристикаларын фаразлауны эшли;»;

«б» пунктчасында «күләме» сүзен «иң чик күләмнәре» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «һәм төп салымнар һәм җыемнар буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен фаразлау методикасын раслый» сүзләрен төшереп калдырырга;

«е» пунктчасында тиешле килешләрдә «бюджет ассигнованиеләрен бүлү» сүзләрен тиешле килешләрдә «бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләмнәрен бүлү» сүзләренә алмаштырырга;

«и» пунктчасында «төп салымнар һәм җыемнар буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен фаразлау методикасы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

«л» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«л) бюджет планлаштыру субъектлары белән берлектә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар исәпләрен үткәрү өчен чыганак күрсәткечләрне җыя һәм гамәлгә ашыра;»;

3 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын эшли;»;

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) бюджет планлаштыру субъектлары тарафыннан тапшырылган түбәндәгеләрне килештерүне гамәлгә ашыра:

чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын;

Татарстан Республикасы расланган дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне;

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салулар рәвешендә яисә Татарстан Республикасы дәүләт милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу рәвешендә бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында, бюджет һәм автоном учреждениеләргә, дәүләт унитар предприятиеләренә дәүләт милке объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектларын (алга таба - дәүләт милке объектларына капитал салулар);

муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны финанслашуга яисә җирле бюджетлардан гамәлгә ашырыла торган муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга субсидияләр бирү турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына тәкъдимнәр;»;

«г» пунктчасында «озак сроклы максатчан программалар һәм бюджет инвестицияләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм дәүләт милке объектларына капитал салулар» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәге мәгълүматларны тапшыра:

дәүләт мөлкәтен, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән файдаланудан һәм реализацияләүдән Татарстан Республикасы бюджетының фаразлана торган керемнәре турында;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре буенча муниципаль милекне, шул исәптән дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен файдаланудан һәм реализацияләүдән фаразлана торган керемнәре турында.»;

5 пунктның «а»  һәм «б» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекләрнең бюджет чыгымнары индекслары турында белешмәләр;

б) чираттагы финанс елына һәм план чорына физик һәм (яисә) юридик затларга дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар турында Татарстан Республикасы бюджет планлаштыру субъектлары белән килештерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын.»;

6 пунктта:

«а»  пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«в» пунктчасында «һәм чыгымнар төрләре» сүзләрен «, төркемнәргә, төркемчәләргә, чыгым төрләре элементларына» сүзләренә, «озак сроклы республика максатчан программалары һәм бюджет инвестицияләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм дәүләт милке объектларына капитал салулар» сүзләренә алмаштырырга;

«д» һәм «е» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«д) чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елында Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртү турында һәм план чорының икенче елына Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре структурасы турында, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт милке объектларына капитал салулар әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен үзгәртү хакында тәкъдимнәр әзерли;

е) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру турында хисаплар, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт милке объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру турында хисаплар төзиләр;»;

«з» пунктчасына «һәм план чоры» сүзләрен өстәргә;

9 пунктта «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

10 – 13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты агымдагы финанс елның 30 июненә кадәр:

а) чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслый, шулай ук Татарстан Республикасы расланган дәүләт программаларына кертелә торган үзгәрешләр кирәк булганда;

б) Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт милке объектларына капитал салуларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында актлар (актларга үзгәрешләр кертә).

11. Бюджет планлаштыру субъектлары агымдагы финанс елның 15 июненә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына дәүләт милке объектларына чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап капитал салуларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр җибәрә.

12. Бюджетны планлаштыру субъектлары агымдагы елның 15 июненә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына чираттагы финанс елына һәм (яисә) план чорының беренче елында Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртү буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектлары белән бәйле өлешендә план чорының икенче елына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларына капитал салуларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы дәүләт норматив хокукый актлары (карарлар) проектларына үзгәрешләр белән җибәрә.

13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты агымдагы финанс елның 20 сентябренә кадәр карый:

а) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын булдыруның шартларын һәм төп бурычларын билгеләүче төп юнәлешләре;

б) чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап Татарстан Республикасының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен кыскарту (структураны үзгәртү) турында тәкъдимнәр;

в) Татарстан Республикасы бюджетыннан чираттагы финанс елыннан яисә капиталь кертемнәрнең план чорыннан башлап әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр.»;

14 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты кертелүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча:

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп характеристикаларын фаразлауны хуплый;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының төп характеристикаларын раслый;

кабул ителә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми (иң чик) күләмен бүлүне хуплый;

Татарстан Республикасы бюджеты турында һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында законнар проектларын әзерләү өчен кирәкле башка карарлар кабул итә.»;

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

15 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта:

«а» пунктчасының икенче абзацында «15 сентябрь» сүзләрен «15 август» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) агымдагы финанс елның 1 сентябренә кадәр бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүнең расланган методикасын үзгәртү турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны муниципаль берәмлекләрнең финанс органнарына (кирәк булганда) җибәрә.»;

19 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) бюджет планлаштыру субъектлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджеты чараларын чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы бюджеты чараларын баш бүлүчеләргә, бүлекчәләренә, максатчан статьяларына, төркемнәренә, чыгым төрләре элементларына, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре элементларына (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм капиталь төзелеш объектлары буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүгә кагылышлы өлештә - шулай ук Татарстан

Республикасы Икътисад министрлыгына), чыгым йөкләмәләренең планлы реестрларына һәм бюджет ассигнованиеләрен нигезләү, тиешле бюджет чараларын бүлүчеләргә бюджет ассигнованиеләрен нигезләү буенча тәкъдимнәр, тиешле бюджет планлаштыру субъектларын алып баруга кертелгән мәсьәләләр өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектына аңлатма кертергә;»;

20 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын караган көннән алып биш эш көненнән артмаган срокта:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин